КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 май г.Казань № 552

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче; 2018 ел, 14 июнь, 472 нче; 2019 ел, 13 июнь, 487 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 748 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 926 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 993 нче; 2020 ел, 11 февраль, 86 нчы; 2020 ел, 9 апрель, 264 нче; 2020 ел, 30 апрель, 353 нче;

2020 ел, 28 сентябрь, 878 нче; 2021 ел, 20 май, 347 нче; 2021 ел, 9 август, 692 нче, 2021 ел, 21 декабрь, 1258 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «3. | Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан, Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керә торган җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү турында гаризалар кабул итү»; |

“Федераль салым хезмәтенеж Татарстан Республикасы буенча идарәсе” бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
|---|---|
| 1. | Юридик затларны, индивидуаль эшмәкәрләр буларак физик затларны һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларын дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Кызыксынучы затларга дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү |
| 3. | Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү (физик һәм юридик затлар сораулары буенча әлеге реестрдан өземтәләр бирү өлешендә, салым серенә ия булган мәгълүматлардан тыш) |
| 4. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы һәм Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны һәм документларны (физик һәм юридик затларның сораулары буенча әлеге реестрлардан өземтәләр бирү өлешендә, файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматларга ия өземтәләрдән тыш) бирү |
| 5. | Салым түләүчеләргә, җыемнар түләүчеләргә, иминият кертемнәрен түләүчеләргә һәм салым агентларына салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар, салымнар һәм җыемнарны, иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү тәртибе, салым түләүчеләрнең, җыемнар түләүчеләрнең, иминият кертемнәре түләүчеләрнең һәм салым агентларының хокуклары һәм бурычлары, салым органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының вәкаләтләре (салым түләүче (җыемнар түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү турындагы белешмәне кабул итү һәм бирү өлешендә) турында бушлай мәгълүмат җиткерү (шул исәптән язма рәвештә); салым (бурыч) түләүнең үткән срогы белән (срогы булмаган) исәпләүләр, шулай ук Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасын кулланып күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан формалаштырылган пенялар турында, ПД № (салым) формасы |

| | |
|---|---|
| | буенча бастырылган түләү документы) турында хәбәр бирү өлешендә |
| 6. | Физик затның транспорт салымы, җир салымы, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым ташламалары бирү турындагы гаризасын кабул итү |
| 7. | Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайлап алынган объектлары турында хәбәрнамә кабул итү |
| 8. | Сайлап алынган, җир салымы буенча салым тотып калынган җир кишәрлеге турында хәбәрнамә кабул итү |
| 9. | Салым хәбәрнамәсе бирү турында гариза кабул итү |
| 10. | Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым салу объектының һәлак булуы яки юк ителүе турында гариза кабул итү |
| 11. | Физик затлар булган салым түләүчеләрдән физик затлар керемнәренә салым буенча салым декларацияләрен (3-НДФЛ формасы) кәгазь чыганакта кабул итү |
| 12. | Физик затның салым органында исәпкә кую турында гаризасын кабул итү һәм физик затка исәпкә кую турында таныклык бирү (яңадан бирү) |
| 13. | Индивидуаль эшкуарлардан патент алуга гариза кабул итү |
| 14. | Физик затлар тарафыннан түләнә торган тиешле салымнар буенча салым салу объектлары дип таныла торган күчемсез мөлкәт объектлары һәм (яки) транспорт чаралары булу турында хәбәрләр кабул итү |
| 15. | Салым оешмасы хәбәрнамәсендә күрсәтелгән мәгълүматларны тәгаенләү турында салым оешмасы хәбәрнамәсенә гариза кабул итү |
| 16. | Физик затлар өчен салым түләүченең шәхси кабинетына керү турында гариза кабул итү |
| 17. | Транспорт салымы буенча салым салу объектының һәлакәте яки юк ителүе турында гариза кабул итү |
| 18. | Абонент хезмәте күрсәтү рәвешендә күрсәтелә торган, бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсында булган мәгълүматны бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорау кабул итү |
| 19. | Салым түләүче - индивидуаль эшкуар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариус, адвокат кабинетын гамәлгә куйган адвокат, индивидуаль эшкуар булмаган физик зат тарафыннан почта буенча салым органы тарафыннан салым органнары тарафыннан салымнар һәм җыемнар турындагы законнар белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрдә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган документлар җибәрү өчен адрес бирү турында гаризалар кабул итү |
| 20. | Салым түләүче физик затның транспорт чарасын мәҗбүри тартып алуга бәйле рәвештә транспорт салымын исәпләүне туктату турындагы гаризасын кабул итү |
| 21. | Салым түләүченең, җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең яисә салым агентының бердәм салым счеты буенча уңай, тискәре һәм нуль сальдосы белешмәсе формалашкан датага торышы турында белешмә бирү хакында гарызнамә кабул итү |
| 22. | Бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акчаларның суммалары булу турында белешмә бирү хакында гарызнамә кабул итү |

| | |
|---|---|
| 23. | Бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән һәм (яисә) бердәй салым түләве буларак танылa торган акчалар суммасының яисә бердәм салым түләве сыйфатында саналмаган акчалар суммасын бирү һәм аны бирү форматы турында гарызнамә кабул итү |
| 24. | Салым түләүченең, җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының пенялар, штрафлар, процентлар буенча недоимка һәм (яисә) бурыч барлыгы турында мәгълүмат бирүгә ризалыгын кабул итү»; |

түбәндәге эчтәлекле «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлек» бүлекчәсен өстәргә:

| «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге | |
|---|---|
| 1. | Ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты бирү |
| 2. | Ана (гаилә) капиталының чараларын (чараларының өлешен) файдалану турында гаризаны карау |
| 3. | Россия Федерациясендә гражданнарның аерым категорияләренә айлык акчалата түләү билгеләү |
| 4. | Пенсия тупланмалары чараларын формалаштырганда һәм инвестицияләгәндә һәм алар буенча карарлар кабул иткәндә иминләштерелгән затларның хокукларны гамәлгә ашыру максатларында аларның гаризаларын (хәбәрнамәсен) карау |
| 5. | Мәҗбүри пенсия иминияте системасында теркәлү максатларында гражданнардан анкет кабул итү, шул исәптән иминләштерелгән затлардан иминият таныклыгы дубликатын алмаштыру яисә бирү турында гаризалар кабул итү |
| 6. | Иминият пенсияләрен, тупланма пенсияләрне һәм дәүләт пенсия тәэминаты буенча пенсияләрне билгеләү |
| 7. | Иминият пенсияләрен, тупланма пенсияләрне һәм дәүләт пенсия тәэминаты буенча пенсияләрне түләү |
| 8. | «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсән) исәпкә алу турында» һәм «Россия Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акчаларны инвестицияләү турында» федераль законнар нигезендә иминләштерелгән затларга мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы шәхси счетлары торышы турында мәгълүмат бирү |
| 9. | Социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гражданнарга мәгълүмат бирү |
| 10. | Пенсия (башка түләүләр) күләме турында гражданнарга белешмәләр бирү |
| 11. | Пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә кертү турында гражданнарга мәгълүмат бирү |
| 12. | Шәхси счетындагы теркәлгән затның хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр бирү |
| 13. | Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында инвалид тарафыннан идарә ителә торган транспорт чарасы яки |

| | |
|---|---|
| | инвалидны һәм (яки) инвалид баланы йөртүче транспорт чарасы турында мәгълүматлар урнаштыру өчен гаризалар кабул итү |
| 14. | Атом-төш сынаулары һәм техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга компенсацияләр һәм акчалата түләүләр рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү |
| 15. | Хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына акчалата түләүләр һәм компенсацияләр рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү |
| 16. | Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга), яисә аларның законлы вәкилләренә транспорт чаралары хуҗаларының граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча алар түләгән иминият премиясенең 50 проценты күләмендә компенсация бирү |
| 17. | Чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер мәртәбә пособие бирү |
| 18. | Оешмаларны бетерүгә, физик затлар тарафыннан индивидуаль эшкуарлар сыйфатында эшчәнлекне туктатуга, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар тарафыннан вәкаләтләрне туктатуга һәм һәм адвокат статусын туктатуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлеге федераль законнар нигезендә дәүләт теркәве һәм (яисә) лицензияләштерелергә тиешле башка физик затлар эшчәнлеге туктатылуга бәйле рәвештә бала туганда йөклелек чорында эштән азат ителгән хатын-кызларга, йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, һәм бала карау буенча отпуск чорында эштән азат ителгән затларга, шулай ук вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга, шул исәптән һөнәри белем бирү оешмаларында, югары белем бирү мәгариф оешмаларында, өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында һәм фәнни оешмаларда көндезге бүлектә белем алучыларга бер тапкыр бирелә торган пособие бирү |
| 19. | Чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие бирү |
| 20. | Оешмаларны бетерүгә, физик затлар тарафыннан индивидуаль эшкуарлар сыйфатында эшчәнлекне туктатуга, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар тарафыннан вәкаләтләрне туктатуга һәм һәм адвокат статусын туктатуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлеге федераль законнар нигезендә дәүләт теркәве һәм (яисә) лицензияләштерелергә тиешле башка физик затлар эшчәнлеге туктатылуга бәйле рәвештә бала тәрбияләгәндә йөклелек чорында эштән азат ителгән хатын-кызларга, йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, һәм бала карау буенча отпуск чорында эштән азат ителгән затларга, шулай ук вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга, шул исәптән һөнәри белем бирү оешмаларында, югары белем бирү мәгариф оешмаларында, өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында һәм фәнни оешмаларда көндезге бүлектә белем алучыларга бер тапкыр бирелә торган пособие бирү |

| | |
|---|---|
| 21. | Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие бирү |
| 22. | Оешмаларны бетерүгә, физик затлар тарафыннан индивидуаль эшкуарлар сыйфатында эшчәнлекне туктатуга, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар тарафыннан вәкаләтләрне туктатуга һәм һәм адвокат статусын туктатуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлеге федераль законнар нигезендә дәүләт теркәве һәм (яисә) лицензияләштерелергә тиешле башка физик затлар эшчәнлеге туктатылуга бәйле рәвештә бала тәрбияләгәндә йөклелек чорында эштән азат ителгән хатын-кызларга, йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, һәм бала карау буенча отпуск чорында эштән азат ителгән затларга пособие бирү |
| 23. | Беренче бала тууга (уллыкка (кызлыкка) алынуга) бәйле рәвештә айлык түләү бирү |
| 24. | Бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә ай саен бирелә торган пособие бирү |
| 25. | Иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү (күчерү) өчен нигезләр булып хезмәт иткән документларны, шулай ук иминият кертемнәрен исәпләү дөреслеген һәм үз вакытында түләүне (күчерүне) раслый торган документларны кабул итү |
| 26. | Вакытлыча эшкә сәләтсез булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча хокук мөнәсәбәтләренә ирекле рәвештә кергән затларны теркәү һәм теркәүгә алу исәбеннән төшерү |
| 27. | Хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе төзегән иминиятләштерүче физик затларны теркәү һәм теркәүгә алу исәбеннән төшерү |
| 28. | Гражданлык-хокукый шартнамә төзүгә бәйле рәвештә, иминият кертемнәрен түләргә тиешле иминләштерүче физик затларны теркәү һәм исәптән төшерү |
| 29. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр белән һәм ветераннар арасыннан аерым категориядәге гражданнарны протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия әйберләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалидлар мөстәкыйль сатып алган техник тернәкләндерү чаралары өчен (ветераннарга протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре) компенсация түләү һәм (яисә) инвалидларның озатучы этләрне тотуга һәм аларга ветеринария хезмәте күрсәтүгә түләнгән хезмәтләр чыгымнарын еллык акчалата компенсацияләү (инвалидларга тернәкләндерүнең техник чараларын һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр һәм ветераннар арасыннан аерым категориядәге гражданнарны протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия әйберләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалидлар мөстәкыйль сатып алган техник тернәкләндерү чаралары өчен (ветераннарга протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре) компенсация түләү һәм (яисә) инвалидларның озатучы этләрне тотуга һәм аларга ветеринария хезмәте күрсәтүгә түләнгән хезмәтләр чыгымнарын еллык акчалата компенсацияләү турында гариза бирү өлешендә) |

| | |
|---|---|
| 30. | Социаль хезмәтләр җыелмасы, дәүләт социаль ярдәмен алу хокукына ия гражданнарга төп авыруларны профилактикалау максатларында гамәлгә ашырыла торган медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар бирү һәм дәвалану урынына шәһәрара транспортта бушлай бару-кайту рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү |
| 31. | Россия Федерациясе территориясендә картлык һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучылар һәм Ерак Төньяк районнарында яшәүче һәм аларга тиңләштерелгән җирлекләрдә яшәүче пенсионерларга ял итү урынына бару-кайту бәясен түләүгә чыгымнарны компенсацияләү»; |

«Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» бүлекчәсен үз көчен югалткан дип танырга;

«Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге» бүлекчәсен үз көчен югалткан дип танырга;

«Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе» бүлекчәсен үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле «Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы» бүлекчәсен өстәргә:

| «Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы | |
|---|---|
| 1. | Спорт ярышларына бару өчен шәхсиләштерелгән картаны рәсмиләштерү гаризасы буенча шәхесне идентификацияләү процедурасын узу»; |

түбәндәге эчтәлекле «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсе өстәргә:

| «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе территориясеннән читкә чыгарылырга тиешле Россия рәсми документларында апостиль кую |
| 2. | Теркәлгән коммерциягә карамаган оешмалар турында физик һәм юридик затларга мәгълүмат бирү»; |

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «II. Республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары хезмәтләре | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | |
| 1. | Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү |

| | |
|---|---|
| 2. | Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда (дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 3. | Татарстан Республикасында эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 4. | Татарстан Республикасында түләүле җәмәгать эшләре уздыруны оештыру (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 5. | Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш булган вакытта,эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 6. | Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, һөнәри белем алган яки эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, индивидуаль эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) булышлык күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 7. | Татарстан Республикасында хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 8. | Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 9. | Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына һәм эшсез гражданнарга күченгәндә ярдәм күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 10. | Эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү, башка җирлектә укытуны да кертеп (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул итү өлешендә) |
| 11. | Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү |
| 12. | Дәүләт социаль ярдәмен билгеләү, шул исәптән социаль контракт нигезендә |
| 13. | «Хезмәт ветераны» исемен бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгын бирү, «Хезмәт ветераны» таныклыгы дубликатын бирү |
| 14. | «Россиянең мактаулы доноры» күкрәк тамгасы белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләү билгеләү |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе | |
| 1. | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар һәм граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу фактының булуын яисә булмавын раслый торган башка документлар (белешмәләр) бирү |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | |
| 1. | Эшмәкәрләрне дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль, шулай ук күпфункцияле үзәкләр офисларыннан күпфункцияле үзәкләр хезмәткәрләре белән видеоэлемтә аша үзмәшгуль эш итүче буларак эшчәнлек башкару мәсьәләләре буенча консультацияләү |
| Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | |
| 1. | Агач әзерләү һәм урман үсентеләрен үз ихтыяҗлары өчен сату-алу шартнамәсе проектын әзерләү турында карар кабул итү |
| 2. | Урман фонды җирләре чикләрендә сатулар үткәрмичә генә арендага урман кишәрлекләрен бирү |
| 3. | Урман кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү |
| 4. | Урман кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү |
| 5. | Урман фонды җирләре чикләрендә аукцион нәтиҗәләре буенча арендага урман кишәрлеген бирү |
| 6. | Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы үткәрү |
| Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | |
| 1. | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм Мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт итүгә үзгәрешләр кертү) |
| 2. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнары) территорияләрендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге төзү эшләрен башкаруга рөхсәт кәгазе бирү |
| 3. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| 4. | Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары, муниципаль районнары) территорияләрендәге су объектында ясалма җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга рөхсәт кәгазе бирү |
| Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү һәм яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү, рөхсәтне вакытыннан алда туктату |
| 2. | Төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук төзү яисә реконструкцияләү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләр (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә план- |

| | |
|---|---|
| | лаштырыла торган хосусый автомобиль юлларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү |
| 3. | Төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук төзү яисә реконструкцияләү ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләр (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырыла торган хосусый автомобиль юлларын куллануга кертүгә рөхсәт бирү |
| 4. | Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты карталарын рәсмиләштерү, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты карталарын яңадан рәсмиләштерү |
| Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе | |
| 1. | Тракторларга, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарга һәм аларның тагылмаларына техник тикшерү үткәрү |
| 2. | Тракторларны, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарны һәм аларның тагылмаларын (Россия Федерациясе Кораллы Көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) теркәү һәм исәпкә алудан төшерү, аларга дәүләт теркәү билгеләре бирү |
| Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | |
| 1. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү |
| 2. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлекләрен милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытта) файдалануга, түләүсез файдалануга сатулар үткәрмичә бирү |
| 3. | Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен билгеле бер категориягә кертү яисә җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү |
| 4. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү |
| 5. | Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү |
| 6. | Дәүләт милкендәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә |
| 7. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү |
| 8. | Дәүләт милкендәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү |
| 9. | Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне бирү |
| 10. | Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген сатуларда бирү |
| 11. | Территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | |
| 1. | Спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү |
| 2. | Спорт разрядларын бирү |
| Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе | |
| 1. | Алкоголь продукциясен ваклап сатуны лицензияләү (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре җитештерә торган шәрабны, күбекле шәрабны (шампанский) ваклап сатуны лицензияләүдән тыш) |
| Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | |
| 1. | Федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендәге аучылык ресурсларыннан, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән имезүчеләрдән һәм кошлардан тыш, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр бирү (Татарстан Республикасының һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләренә аучылык ресурсларын аулауга һәвәскәрләр һәм спорт максатларында рөхсәтләр бирү өлешендә, кыргый тояклы хайваннарны аулауга рөхсәтләр бирүдән тыш) |
| 2. | Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару |
| 3. | Тиешле рөхсәтсез сакланган яисә Татарстан Республикасы территориясендә табылган кораллар, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне үз иреге белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләк билгеләү һәм түләү |
| 4. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| 5. | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм Мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт итүгә үзгәрешләр кертү) |
| 6. | Төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәне җибәрү |
| 7. | Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамәне җибәрү |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | |
| 1. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затлар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар категориясенә караган затлар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган һәм 23 яше тулган, торак урыннар белән тәэмин ителергә |

| | |
|---|---|
| | тиешле балалар арасыннан булган затлар исемлегенә кертү турында гаризалар кабул итү |
| 2. | Каникуллар вакытта балаларның ялын оештыру (дәүләт учреждениеләрендә әлеге хезмәтне күрсәтү өлешендә) |
| Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе | |
| 1. | Гражданнарның «Суд эшчәнлеге» Россия Федерациясе дәүләт автоматлаштырылган системасыннан файдалану мөмкинлеге юлы белән күпфункцияле үзәкләр аша электрон рәвештә гомуми юрисдикция судларына документлар бирү һәм гомуми юрисдикция судыннан документлар алу мөмкинлеген тәэмин итү |
| Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты | |
| 1. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| 2. | Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм Мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт итүгә үзгәрешләр кертү) |
| Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе | |
| 1. | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү |
| 2. | Техник халәттә йорт эчендәге һәм (яисә) квартал эчендәге газ җиһазларын техник таләпләргә туры килә торган техник халәттә йорт эчендәге һәм (яисә) квартал эчендәге газ җиһазларын тоту буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан гамәлгә ашырыла башлау, йорт эчендәге һәм (яисә) квартал эчендәге газ җиһазларының яисә аларның состав өлешләренең техник торышын билгеләү, әлеге җиһазларның төзексезлеген эзләү һәм ачыклау, шулай ук аны алга таба куллану мөмкинлеген билгеләү турында хәбәрнамәләр кабул итү һәм исәпкә алу |
| Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты | |
| 1. | Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә физик һәм юридик затларны мәгълүмат белән тәэмин итү, архив белешмәләре, архив өземтәләре һәм архив документлары күчермәләре бирү»; |

IV бүлектә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
